| ГЛАВА МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ЛЕНИНОГОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН», МЭР ГОРОДА ЛЕНИНОГОРСКА | | «ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШЛЫГЫ ЛЕНИНОГОРСК ШӘҺӘРЕ МЭРЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **К А Р А Р**

21-05-2020 г.Лениногорск № 65

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Түбән Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Генераль планы проектын карау буенча гавами тыңлаулар үткәрү турында

Халыкның муниципаль хокукый актлар проектлары буенча фикер алышуда катнашу хокукын үтәү, җир кишәрлекләре хокук ияләренең уңай тормыш шартларын, хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 маддәсе, 5.1 ст., 28 Шәһәр төзелеше кодексы, «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1.Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2015 елның 15 октябрендәге 854 номерлы карары нигезендә әзерләнгән Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Түбән Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планына үзгәрешләр кертү проектын карау буенча гавами тыңлаулар үткәрелә башлау турында түбәндәге эчтәлекле эчтәлекле мәгълүмат бирергә: нигезләү материаллары (текст формасында), Территориаль планлаштыру турында нигезләмә, заманча файдаланудагы Карта, җирлекләрнең функциональ зоналары картасы, территориядән файдалануның махсус шартлары булган зоналар чикләре картасы, җирле әһәмияттәге объектларны урнаштыру планлаштырыла торган картасы.

2.Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Түбән Чыршылы авыл җирлге» муниципаль берәмлегенең генераль планына үзгәрешләр кертү проектын карау буенча гавами тыңлаулар уздырырга.

3.2020 елның 25 маена кадәр Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Түбән Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге генераль планына үзгәрешләр кертү проектын түбәндәге рәсми сайтта: http://Leninogorsk.tatarstan.ru «Шәһәр төзелеше» бүлегендә урнаштырырга.

4.2020 елның 25 маенда Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Түбән Чыршылы авыл җирлеге » муниципаль берәмлегенең генераль планына үзгәрешләр кертү проекты экспозициясен түбәндәге адрес: Татарстан Республикасы, Лениногорск муниципаль районы, Түбән Чыршылы авылы, Үзәк урамы, 56 йорт, Югары Чыршылы авылы, Горная ур., 27 й. буенча ачып җибәрергә.

Проект экспозициясе белән танышу вакытын авыл җирлеге администрациясе бинасында 9.00 сәгатьтән 11.00 сәгатькә кадәр һәм 14.00 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр билгеләргә.

Экспозиция эше барышында «Түбән Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына экспозициягә килүчеләргә консультация бирүне оештырырга.

5.Гавами тыңлауларда катнашучыларга Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Түбән Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү проектына кагылышлы тәкъдимнәрен һәм искәрмәләрен түбәндәге адрес буенча «Түбән Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы исеменә язма рәвештә кертергә: ТР, Лениногорск муниципаль районы, Түбән Чыршылы авылы, Үзәк урамы, 56 йорт, электрон рәвештә: Ncher.Len@tatar.ru 2020 елның 25 маеннан чорында 2020 елның 25 июненә кадәр, яисә ачык тыңлауларда катнашучылар җыелышын үткәрү барышында телдән.

6.Гавами тыңлауларда катнашучылар җыелышын 2020 елның 17 июненә, 14.00 сәгатьтә Түбән Чыршылы авылы, Үзәк урамы, 56 нчы йорт адресы буенча билгеләргә.

7.Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында гавами тыңлаулар башлану турында әлеге хәбәрне түбәндәге адрес буенча: (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә бастырып чыгарырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Түбән Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы Н.Я.Хәйруллинага йөкләргә.

Р.Г. Хөсәенов

В.Н. Маркелова
5-28-28